# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Әмәкәй авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 нче елның 18 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Әмәкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең ) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 1000 (бер мең) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРДА махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кышкы һәм җәйге чорда Әмәкәй авылы эчендәге юлларны карап тоту, и.Фәррахов урамы, Киров тыкрыгы, Киров урамы, Гагарин урамы, Базар урамы, Вахитов урамы, Ленин урамы,революция урамы буенча кардан чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

- Әмәкәй авылының Киров тыкрыгына янгын гидрантлары урнаштыру;
- И. Фәррахов урамы, Киров тыкрыгы, Киров урамы, Гагарин урамы буенча светодиодлы лампаларны сатып алу, ремонтлау һәм яңадан урнаштыру һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү,
- клуб түбәсен ремонтлау;
- җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- "Сабантуй"паркын төзекләндерү;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм зиратны тоту;
- су күтәрү манарасы территориясен тоту, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
- чүплекне рекультивацияләү;

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 243 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 139, бу 57% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 139 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең Әмәкәй авылы торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Әмәкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең ) сум күләмендә,I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кышкы һәм җәйге чорда Әмәкәй авылы эчендәге юлларны карап тоту, и.Фәррахов урамы, Киров тыкрыгы, Киров урамы, Гагарин урамы, Базар урамы, Вахитов урамы, Ленин урамы,революция урамы буенча кардан чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

- Әмәкәй авылының Киров тыкрыгына янгын гидрантлары урнаштыру;

- И. Фәррахов урамы, Киров тыкрыгы, Киров урамы, Гагарин урамы буенча светодиодлы лампаларны сатып алу, ремонтлау һәм яңадан урнаштыру һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү,

- клуб түбәсен ремонтлау;

- җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын оештыру һәм үткәрү;

- "Сабантуй"паркын төзекләндерү;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм зиратны тоту;

- су күтәрү манарасы территориясен тоту, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

- чүплекне рекультивацияләү;

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл

җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы: И.И.Шакирҗанова.